РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
БУИНСКИЙ МУНИЦИПАЛЬНЫЙ
РАЙОН СОВЕТ
НОВОТИНЧАЛИНСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
БУА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
ЯҢА ТИНЧӘЛЕ
АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ
СОВЕТЫ

РЕШЕНИЕ КАРАР

30 декабрь 2022 ел № 1-62

Татарстан Республикасы Буа муниципаль районы Яңа Тинчәле авыл җирлеге Советының «Җир салымы турында» 2019 елның 23 октябрендәге 79-1 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында

Россия Федерациясе Салым кодексы нигезендә, Татарстан Республикасы Буа муниципаль районының Яңа Тинчәле авыл җирлеге советы

КАРАР КАБУЛ ИТТЕ:

1. Татарстан Республикасы Буа муниципаль районы Яңа Тинчәле авыл җирлеге Советының «Җир салымы турында» 2019 елның 23 октябрендәге 79-1 номерлы Бюрган авыл җирлеге советы карарына (өстәмәләр һәм үзгәрешләр белән) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 1 пунктның 4 статьясына түбәндәге эчтәлекле 1.3 пунктча өстәргә.:

«1.3. «Россия Федерациясендә (алга таба - хәрби хезмәткәрләр) һәм аларның гаилә әгъзаларын өлешчә мобилизацияләү турында» Россия Федерациясе Президентының 2022 елның 21 сентябрендәге 647 номерлы Указы нигезендә Россия Федерациясе Хәрби Көчләренә мобилизация буенча хәрби хезмәткә чакырылган Татарстан Республикасы Буа муниципаль районы Яңа Тинчәле авыл җирлеге территориясендә яшәүче Россия Федерациясе гражданнары.

Хәрби хезмәткәрләрнең гаилә әгъзалары дигәндә түбәндәгеләр аңлашыла:

1) хәрби хезмәткәрләр белән никахта торучы ир яисә хатын;

2) 18 яшькә җитмәгән яки аннан өлкәнрәк булган, әгәр алар 18 яшькә җиткәнче инвалид булсалар, шулай ук белем бирү оешмаларында көндезге уку формасы буенча укучы, уку тәмамланганчы, әмма алар 23 яшькә җиткәнче хәрби хезмәткәр балалары;

3) хәрби хезмәткәрнең әти-әнисе.».

2. Әлеге карарның 1 пунктының 1.1 пунктчасы нигезләмәләренең гамәлдә булуы 2021-2022 елның салым чорлары өчен җир салымын исәпләүгә бәйле хокук мөнәсәбәтләренә кагыла.

3. Әлеге карар Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында (http:pravo.tatarstan.ru), шулай ук Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре Порталында Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә (http//buinsk.tatarstan.ru) рәсми басылып чыккан көннән законлы көченә керә.

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үземдә калдырам.

Совет рәисе, Буа муниципаль районының
Яңа Тинчәле авыл җирлеге башлыгы Р.К. Мадышев